| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**__09/10/2017_____________** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ __2555________** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районының 2013-2017 авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү программасы буенча Зеленодольск шәһәренең Комсомол урамындагы 36 нчы торак йортны коммуникацияләрдән өзү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күп фатирлы йортлары исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карары, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 06 февралендәге 176 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2017 елның 31 августындагы 2311 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының 2017 елның 18 сентябрендәге 233 номерлы ведомствоара комиссиясе бәяләмәсен исәпкә алып, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольскгаз» ЭПУ, «Зеленодольск-Водоканал» предприятиесенә - «Водоканалсервис» ААҖ филиалы, Идел буе бүлекчәсенең Зеленодольск ОКО - «Татэнергосбыт» ААҖ филиалына түбәндәге адрес буенча авария хәлендәге торак йортның тиешле төрен коммуникацияләрдән өзәргә тәкъдим итәргә:

   -ТР, Зеленодольск ш., Комсомол ур., 36 нчы йорт.

2. «Зеленодольск муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программасы буенча, күчерү вакытына кадәр гражданнарны теркәүне саклап калып, Зеленодольск шәһәренең Комсомол урамындагы 36 нчы йорттагы барлык торак биналарга шәхси счетларны ябарга.

3. «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ билгеләнгән тәртиптә, Зеленодольск шәһәре, Комсомол урамы, 36 нчы йортның 5 нче, 7 нче урыннарын муниципаль милек реестрыннан

төшереп калдыруны тәэмин итәргә, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешмага күчерелгән йортларның җир кишәрлекләрен тапшырырга.

4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтында яисә «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин